ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» гыйнвар ел № 19

Әгерҗе муниципаль районында
җир кишәрлекләрен сату буенча
ачык аукцион үткәрү турында

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12 статьялары нигезендә, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3.3 ст. 2 п. нигезендә, шулай ук, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әгерҗе муниципаль районында җир кишәрлекләрен сату буенча аукционга куела торган җир кишәрлекләре исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. Җир кишәрлекләрен сату буенча аукцион комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

3. Җир кишәрлекләрен сату буенча аукционнар оештыру һәм үткәрү буенча аукцион комиссиясенә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы торак пунктлары җирләреннән әлеге карарныц 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен сату буенча аукцион үткәрергә.

4. 3% күләмендә «аукцион адымы» билгеләргә.

5. Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына аукцион үткәрү турында белдерүне, аукцион үткәрү датасы һәм вакыты турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе рәсми сайтында https://torgi.gov.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасынд урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э. А. Поносовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С.Авдеев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
23 гыйнвар 2020 ел № 19
карарына 1нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районында җир кишәрлекләрен сату буенча аукционга куела торган җир кишәрлекләре исемлеге**

| Лот № | Җир кишәрлегенең адресы | Җир кишәрлегенең максатчан билгеләнеше | Җир кишәрлегенең мәйданы | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Участокның башлангыч бәясе, сум. | Аукцион адымы (3%), сум | Беренчел кертем (20%), сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | ТР, Әгерҗе, К.Маркс ур., 101 | Җитештерү базасын урнаштыру өчен | 17 | 16:01:220401:1477 | 9000 | 270 | 1800 |
| 2. | ТР, Әгерҗе, К.Маркс ур., 101 | Җитештерү базасын урнаштыру өчен | 400 | 16:01:220401:1478 | 210000 | 6300 | 42000 |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
23 гыйнвар 2020 ел № 19
карарына 2нче кушымта

**Җир кишәрлекләрен сату буенча аукцион комиссиясе составы**

1) Поносов Э.А. – Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;
2) Андреева И.Е. – Әгерҗе муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе урынбасары;
3) Лукшин П.А. – Әгерҗе муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының контроль һәм исәп бүлеге башлыгы;
4) Рябкова Е.В. – Әгерҗе муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече;
5) Короткова Л.В. – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече.